**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2025 елның 12 сентябрендәге 2871 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Идел буе районында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 110117 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:24:150305:27, 16:24:150305:446, 16:24:150305:447;
- хокуклар чикләнә торган кадастр кварталы – 16:50:150305;
- урнашкан урыны: Казан шәһәре, Идел буе районы;
- билгеләүнең максаты: линия объектлары булган инженерлык корылмалары участокларын (өлешләрен) реконструкцияләү, капиталь ремонтлау;
- билгеләү вакыты: 2 ел;

1.2. гариза бирүче: «Главтатдортранс» дәүләт казна учреждениесе;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 1 пункты, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Казан шәһәр округының Генераль планы, Татарстан Республикасы Казан муниципаль берәмлеге, Лаеш территориясендә «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында М-12 «Восток» трассасыннан алып Казан – Оренбург – Акбүләк – Казахстан Республикасы белән чик автомобиль юлына кадәр автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү» линия объектын урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне ызанлау проектын раслау турындагы карар.

2. Сервитутны гамәлгә ашыру белән бәйле рәвештә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт 18 айны тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлар нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1-2 номерлы кушымталар нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүматлар кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны, әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


7. «Главтатдортранс» дәүләт казна учреждениесенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, алардан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 12 сентябрендәге
2871 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләре**




| Масштаб: 1:10000<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| (кызыл төс) | Ачык сервитутлар (проектлана торган) |
| (зәңгәр контур) | Җир кишәрлекләре |
| 16:24:150305 | кадастр кварталы |
| 16:24:150305:27, 16:24:150305:446, 16:24:150305:447 (16:24:000000:154 бердәм җирдән файдалану составында) | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |